# Тәмамлык

***Эш-хәрәкәт белдерүче сүзгә ияреп килгән һәм аның үтәлүенә бәйле предметны, затны күрсәткән иярчен кисәк.*** *Исем* ***яки*** *исем мәгънәсендә килгән сүзләр* ***белән белдерелә, барлык*** *кыек килеш сорауларына* ***һәм бәйлекләр белән килгән сорауларга җавап бирә***.

Кемгә?

Кем хакына?

Кем белән?

Нәрсәгә?

Нәрсә өчен?

Кемдә?

һ.б.

Кемне?

1.**Туган телдә** (нәрсәдә?) **уку бәхетен** (нәрсәне?) берни алыштыра алмый. (Ш.Галиев)

2. Халкыбыз **туган ягына** ( нәрсәгә?) булган **мәхәббәтен** ( нәрсәсен?) **көйгә** (нәрсәгә?) салып та җырлый. (Г.Бәширов)

3. **Корыч белән** ( нәрсә белән?) җәрәхәтләнеп беткән дала өстендә язгы кояш балкый.

( И.Гази)

## Туры

Процесс турыдан-туры төшкән объект. Төшем килеше кушымчасы алган яки алу ихтималы булган тәмамлык.

## Кыек

Процесс турыдан-туры аңа төшмәгән. Ияртүче сүзгә Ю.к.,Ч. к., У.-в.к. кушымчалары, бәйлек,бәйлек сүзләр ярдәмендә ияреүче тәмамлык.

# Туры һәм кыек тәмамлыкларны табыгыз.

1. Сөйләгәчтен кыйссаны, алды тарагымны әни .(Г.Т.)
2. Шуны ул тел хакында язган мәкаләләрендә исбат итә алды.(Г.А.)
3.Кеше чын мәхәббәтне теләүдән, сагынудан,өмет итүдән туктый алмый.(Ә. Е.)
4. Гөлләр сине назлап сөяр.
Кояш көлеп башын ияр. (М.Җ.)



# Ачкыч

1. а) Кыйссаны ( нәрсәне?)- туры тәмамлык,Т.к., б) тарагымны (нәрсәне?)- туры тәм-к, Т.к.;

2.а) Шуны (нәрсәне?)- туры тәм-к, Т.к.; б)тел хакында ( нәрсә хакында?)-кыек тәм-к, исем+ бәйлек.

3. а) Мәхәббәтне( нәрсәне?)- туры тәм-к, Т.к.; б) теләүдән, сагынудан, өмет итүдән ( нәрсәдән?)- кыек тәм-к, Ч.к.

4. а) Сине( кемне?)-туры тәм-к,Т.к., б) башын( нәрсәсен?)-туры тәм-к, Т.к.

Тәмамлыклар кулланып, рәсем буенча хикәя төзегез



# ТЕСТ

1. Тәмамлык җөмләнең
а) фигыль белән белдерелгән кисәген;
б) исем белән белдергән кисәген;
в) теләсә кайсы сүз төркеме белән белдерелгән кисәкне ачыклый.

2. Тәмамлыкның
а) ике; б) өч; в) дүрт төре бар.

3. Туры тәмамлык
а) баш килештәге;
б) төшем килешендәге;
в) баш һәм төшем килешендәге исемнәр һәм исемләшкән сүз төркемнәре белән белдерелә.



4. Туры тәмамлык

а) эш төшә торган туры объектны;

б) эшнең кыек объектын;

в) икесен дә белдерә.

5. Сагындырды әнкәемнең иркәләп уятуы җөмләсендәге бирелгән сүз

а) аергыч; б) тәмамлык; в) ия булып килгән.

6. Ул тагын күзләрен ачты җөмләсендә билгеләнгән сүз

а) чыгыш килешендәге исем белән белдерелгән кыек тәм-к;

б) баш килештәге исем белән белдерелгән туры тәм-к;

в) төшем килешендәге исем белән белдерелгән туры тәм-к.

7. Әти хат укый   җөмләсендә билгеләнгән сүз
а) ия;  б) туры тәмамлык;  в) кыек тәмамлык.

8. Сөйләүче  өчен билгелерәк булган әйбер турында әйткәндә туры тәм-к
а) баш килештәге исем;
б) төшем килешендәге исем белән;
в) икесе белән дә белдерелә.

9. Туры һәм кыек тәмамлыклары булган җөмлә
а) Зөһрә Илнурны авызын ачкан килеш тыңлады;
б) Ул Зөһрәнең күзләренә туры карарга кыймады;
в) Зөһрә әнисенә Илнурны әләкләү өчен йөгереп китте.

# Ачкыч

1. а;
2. а;
3. в;
4. а;
5. а;
6. в;
7. б;
8. б;
9. в.

